Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы
«Түбән Кәминкә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге гражданнары җыены карары

Татарстан
Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең составына керүче Түбән Кәминкә авылы торак пунктында

08 ноябрь 2019 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Түбән Кәминкә авыл җирлегенең Түбән Кәминкә авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

2020 елда Түбән Кәминкә авыл җирлеге территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 500 сум күләмендә үзара салым кертергә 1 төркем инвалидлардан, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, Россия Федерациясе Кораллы Көчләре сафларында хезмәт итүчеләрдән тыш һәм алынган чараларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә җибәрергә:

- Түбән Кәминкә торак пунктларында җәйге һәм кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны төзекләндерү, карап тоту, хезмәт күрсәтү (юл кырыйларын чабу, юл-урам челтәрендәге юл кырыйларын норматив хәлгә китерү, юлларны грейдерлау, урамнарны кышкы чорда кардан чистарту, ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, хезмәтләр өчен түләү), югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу чыгымнары;

- Стелла сатып алу һәм Түбән Кәминкә торак пунктында урнаштыру, проект-смета документлары өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

- урам утларын монтажлау, кую, ремонтлау, карап тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү, торак пунктларда урам утларына кулланган электр энергиясе өчен чыгымнарны түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу;

Түбән Кәминкә торак пунктларында җәмәгать киңлекләрен төзекләндерү, 1 га мәйданга урман культуралары утырту, проект-смета документациясе өчен түләү, югарыда күрсәтелгән эшләрне (хезмәтләрне) башкару өчен кирәкле материаллар сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче
Түбән Кәминкә авыл җирлеге башлыгы Р.Р.Халиков